Татарстан Республикасы Спас муниципаль районы

Аграмак авыл җирлеге Советы

КАРАР

№ 90-1 11.06..2024 ел.

Җирле салымнар буенча бурычларны
түләтүгә өметсез дип тануның
өстәмә нигезләрен билгеләү турында

Россия Федерациясе Салым кодексының 59 статьясының 3 пункты, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында»2024 елның 12 апрелендәге 18-ТРЗ номерлы "Төбәк салымнары суммалары буенча бурычларны түләтү турында "Татарстан Республикасы Законы, Татарстан Республикасы Спас муниципаль районы Аграмак авыл җирлеге муниципаль берәмлеге Уставы нигезендә, Татарстан Республикасы Спас муниципаль районы Аграмак авыл җирлеге Советы

Карар кабул итте:

1.2024 елның 1 гыйнварына аерым салым түләүчеләргә караган җирле салым суммалары өлешендә бурычларны түләтүгә өметсез дип тануның өстәмә нигезләрен билгеләргә:

1) варислар мирас хокукыннан баш тарткан, варислар булмаган яки мирас ачылганнан соң бер ел эчендә мирасны кабул итмәгән очракта үлгән яки үлгән дип игълан ителгән физик затларда бурычлар булу;

2) Россия Федерациясе Салым кодексының 48 статьясында билгеләнгән сроклар тәмамланганнан соң 500 сумнан артмаган суммада физик затларның бурычы булуы.

2. Әлеге карарны Спас муниципаль районының рәсми сайтында http://www.spasskiy.tatarstan.ru һәм хокукый мәгълүматның рәсми порталында (//http:pravo.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга.

3. Әлеге карар рәсми рәвештә басылып чыккан көннән үз көченә керә.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үземдә калдырам.

Аграмак авыл җирлеге
башлыгы Р.Т.Галәветдинова

СОВЕТ АГРАМАКОВСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ